СОВЕТ НИЖНЕУСЛОНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ТҮБӘН ОСЛАН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ — КАРАР

23.06.2016 — с. Нижний Услон — 12-53

4 нче номерлы Түбән Ослан бермандатлы сайлау округы буенча өченче чакырылыш «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге вәкиллекле органына депутатларны өстәмә сайлауларны билгеләү турында

4 нче номерлы Түбән Ослан бермандатлы сайлау округы буенча сайланган өченче чакырылыш «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге вәкиллекле органы депутаты вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылу сәбәпле, 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 10 статьясындагы 6, 7 пунктлары, 6 статьясындагы 4 өлеше, 2007 елның 07 маендагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 105 статьясындагы 1 өлеше, Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлеге Уставының12 статьясы нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районы
Түбән Ослан авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. 2016 елның 18 сентябренә 4 нче номерлы Түбән Ослан бермандатлы сайлау округы буенча өченче чакырылыш «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлеге» вәкиллекле органы депутатларын өстәмә сайлаулар билгеләргә.

2. «Волжская новь» район газетасында әлеге карарны бастырып чыгарырга, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Түбән Ослан авыл җирлеге башлыгы — А. З. Шәйдуллин